**Совет Карашай Сакловского сельского поселения Сармановского муниципального района Республики Татарстан.**
**ИНН 1636001330**
**ОГРН 1021601313128**
**ОКАТО 92253828000**
**Инд.423378,РТ,с.Карашай Саклово, ул.Ленина ,д.100**
**Телефон: 8 85559 4-92-18**

**Татарстан.Республикасы Сармановского муниципаль районы Карашай Саклау авыл җирлеге Советы**
**ИНН 1636001330**
**ОГРН 1021601313128**
**ОКАТО 92253828000**
**Инд.423378,ТР,Карашай Саклау авылы,Ленин ур. 100 йорт**
**Телефон: 8 85559 4-92-18**

РЕШЕНИЕ КАРАР

23 сентябрь 2019 ел № 93

Җирле референдум үткәрү инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы “Россия Федерациясендә җирле үзидәрә оештыруының гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октяберендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 п.,Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Карашай-Саклау авыл җирлеге Уставының 11 статьясы нигезендә, Сарман муниципаль районы Карашай-Саклау авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Карашай-Саклау авыл җирлеге территориясендә җирле референдум үткәрү инициативасы белән чыгарга:«I группа инвалидлар, көндезге бүлек студентлары, хәрби хезмәт узучы хезмәткәрләрдән тыш, Карашай-Саклау авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ кешедән, 2020 елда 300 сум үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне башкаруга тоту белән килешәсезме:

-Карашай Саклау авылы зиратын коймасын тоту;

- Чураш авылы күперенэ вак таш жэю ( вак таш таш ташу);

- Карашай Саклау авылындагы су башнясына янгын краны сатып алу һәм урнаштыру;

- Карашай Саклау авылында Сабантуй мәйданына эскәмияләр сатып алу;

- Карашай-Саклау,Чураш авылларынnда массакулэм чараларга бүләкләр алу (Сабантуй, юбилярлар, Җиңү көне, Өлкәннәр көне, Балаларны яклау көне)

- Карашай Саклау, Чураш авылларында урам яктырткычларын ремонтлау һәм урнаштыру;;

- Чураш авылында урам исемнәре һәм йорт номерлары язылган күрсәткечләр сатып алу;;

-Карашай Саклау, Чураш авылы зиратларында янгын куркынычсызлыгы өчен су савытлары сатып алу;;

- Карашай Саклау, Чураш авылларында көнкүреш калдыкларын һәм чүп-чарларны вакытлыча җыю һәм чистарту.;

- МТЗ-82.1 тракторына ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу;;

-кыш көне Карашай Саклау, Чураш авылларындагы юлларны кардан чистарту;

- Карашай Саклау, Чураш авыллары территорияләрен куак һәм агачлардан чистарту;

- район газетасында некрологларны бастырып чыгару;

ӘЙЕ ЮК?».

2.Әлеге карарны мәгълүмат стендларына һәм авыл җирлегенең рәсми сайтында кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Карашай-Саклау Советы Башлыгы

авыл җирлеге Башлыгы В. В. Хөсниева